ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 12.05.2026 700 КАРАР

**2026 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, салым салынырга тиешле керем күләменең һәм мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыкның «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2026 елның 17 фенвралендәге 65 номерлы хатын исәпкә алып, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге иң чик күләмнәрен билгеләргә:

1.1 һәр гаилә әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләме - 60 300 сум 49 тиен;

1.2 һәр гаилә әгъзасы яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.2.1 ялгыз яшәүче граждан өчен – 2 371 878,00 сум;

1.2.2 ике кешедән торган гаилә өчен – 4 743 756,00 сум;

1.2.3 өч кешедән торган гаилә өчен – 7 115 634,00 сум.

Дүрт кешедән торган һәм аннан артыграк гаилә өчен иң чик күрсәткече гаилә әгъзалары саныннан, гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасыннан һәм торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясеннән исәпләнә.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан мөлкәтендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү исәп-хисабын, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының торак бүлегенә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1. һәм 1.2. бүлекләрендә билгеләнгән чик күрсәткечләрен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә куйганда кулланырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00A6F1760457AE01A4E9F82749523D5258
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 30.01.2026 до 25.04.2027

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта
12.05.2026 700

Һәр гаиләгә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан мөлкәтендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләүнең исәп-хисабы

1. Базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече

СЖ = НП Х РС х РЦ, биредә:

СЖ –базар бәясенең исәп күрсәткече яисә мөлкәтнең иң чик күләме;

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзаларының саны;

РЦ - ТР буенча РФ Төбәкләр үсеше Министрлыгы раслаган торак урын мәйданының бер квадрат метрына уртача исәпләнгән базар бәясе.

1) ялгыз яшәүче гражданин өчен:

СЖ = 18 х 1 х 131 771,00 = 2 371 878 сум.

2) ике кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 2 х 131 771,00 = 4 743 756,00 сум.

3) өч кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 3 х 131 771,00 = 7 115 634,00 сум.

4) дүрт кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 4 х 131 771,00 = 9 487 512,00 сум.

5) биш кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 5 х 131 771,00 = 11 859 390,00 сум.

6) алты кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 6 х 131 771,00 = 14 231 268,00 сум.

7) җиде кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 7 х 131 771,00 = 16 603 146,00 сум.

8) сигез кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 8 х 131 771,00= 18 975 024,00 сум.

9) тугыз кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 9 х 131 771,00= 21 346 902,00 сум.

10) ун кешедән торган гаилә өчен:

СЖ = 18 х 10 х 131 771,00= 23 718 780,00 сум.

2. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү.

Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең иң чик күләмен билгеләү формуласы:

ПД = 0,87 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)-КП) / (0,3 х РС), биредә

ПД- гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе

буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күләме;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

СЖ = НП х РСх РЦ, биредә:

НП - аиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС- гаилә әгъзалары саны;

РЦ - торак урындагы бер квадрат метрның муниципаль берәмлектәге уртача шартларга һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урыннарны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү ӛчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар хакыннан артып китми торган уртача исәпләнгән базар бәясе.

ПС – айга кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма) (елга-8,7%, ягъни аена- 8,7/100/12 = 0,0072);

КП - кредитның бөтен срогы өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (20х12=240 айлар саны);

РС – гаилә әгъзаларының саны;

0,87 – кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 – кредит буенча түләү һәм гаиләнең айлык җыелма кереме нисбәте.

Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2026 елның беренче яртыеллыгына бәясе «Бәяләүчеләр берлеге» коммерциячел булмаган партнерлыкның «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2026 елның 17 февралендәге 65 номерлы боерыгы нигезендә. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы буенча 110 138,75 сум күләмендә билгеләнгән.

Ялгыз яшәүче гражданга яки гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләменең иң чик күрсәткече исәп-хисабы

1) Ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,87 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)-КП) / (0,3 х РС) = 0,87 х2 371 878,0 х 0,0072 / (1 - (1 + 0,0072)-240) / (0,3 х 1) = 14 857,44/0,8213/0,3 = 60 300,49 сум.

2) Ике кешедән торган гаилә өчен:

ПД = 0,87 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,87 х 4 743 756,00 х 0,0072/(1-(1 + 0,0072) $^{-240}$) / (0,3 х 2) = 29 714,88/0,8213/0,6 = 60 300,49 сум.

3) Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,87 х 7 115 634,0 х 0,0072 / (1 - (1 + 0,0072)$^{-240}$)/ (0,3 х 3) = 44 572,33/0,8213/0,9 = 60 300,49 сум.